| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2022 г. Казань № 770-294/тп-2022

2023 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан газ бүлү челтәрләренә газ куллана торган җиһазларны технологик тоташтыруга түләү күләмен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бәяләрен, аны транспортлаштыру хезмәтләренә тарифларны һәм газдан файдалану җайланмасын Россия Федерациясе территориясендә газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карарына, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Газдан файдалану җайланмасын газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләү күләмен һәм (яки) аның зурлыгын билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын раслау турында» 2018 елның 16 августындагы 1151/18 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 20 декабрендәге 45-ПР номерлы утырыш беркетмәсенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан газ куллану җиһазларын газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү күләмен билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү күләме 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән гаризачы категорияләрен тоташтырудан алынмый калган керемнәрен 0,0 мең сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.12.2022 № 770-294/тп-2022
карарына кушымта

## 2023 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан газ бүлү челтәрләренә газ куллана торган җиһазларны технологик тоташтыруга түләү күләме

| т/с | Гаризачылар категориясе | Гаризачының җир кишәрлеге чикләреннән газ бүлү челтәрләренә кадәрге аралык | Технологик ялгау өчен түләү күләме, сум. | |
|---|---|---|---|---|
| | | | өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча | өстәмә хас салымын исәпкә алып<*> |
| 1. | Газ куллана торган җиһаздан проект буенча эш басымы 0,3 МПа артмаган газ бүлү челтәренә кадәрге, туры линия (иң аз аралык) буенча үлчәнә торган ераклык 200 метрдан артмау һәм торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру буенча билгеләнгән тәртиптә расланган төбәк (төбәкара) программа, шулай ук халыкны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган газ белән тәэмин итү объектларының урнашу схемасы нигезендә фәкать газүткәргечләр төзүне генә (траншеясыз ысул белән газүткәргечләр салу һәм газны редукцияләү пункты урнаштыру чараларын башкару зарурлыгыннан башка гына) күздә тоткан чаралар шарты белән, әлеге тоташтыру ноктасында (башка төр гаризачылар өчен) элегрәк тоташтырылган газдан файдалану җиһазы сарыф итә торган газны исәпкә алып, бер сәгатьтә газ сарыф итүнең максималь күләме 5 куб. метрдан артмый торган. | 10 м кадәр (иң күбе) | 26 121,40 | 31 345,68 |
| | | 10 м дан артып, 20 м га кадәр (иң күбе) | 39 182,10 | 47 018,52 |
| | | 20 м артык | 65 303,50 | 78 364,20 |
| 2. | Газ куллана торган җиһаздан проект буенча эш басымы 0,3 МПа артмаган газ бүлү челтәренә кадәрге, туры линия (иң аз аралык) буенча үлчәнә торган ераклык 200 метрдан артмау һәм торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру буенча билгеләнгән | 200 м кадәр (иң күбе) | 65 303,50 | 78 364,20 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тәртиптә расланган төбәк (төбәкара) программа, шулай ук халыкны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган газ белән тәэмин итү объектларының урнашу схемасы нигезендә фәкать газүткәргечләр төзүне генә (траншеясыз ысул белән газүткәргечләр салу һәм газны редукцияләү пункты урнаштыру чараларын башкару зарурлыгыннан башка гына) күздә тоткан чаралар шарты белән, әлеге тоташтыру ноктасында (эшкуарлык (коммерция) эшчәнлеге максатларында газ куллану нияте булган гаризачылар өчен) элегрәк тоташтырылган газдан файдалану җиһазы сарыф итә торган газны исәпкә алып, бер сәгатьтә газ сарыф итүнең максималь күләме 15 куб. метрдан артмый торган. | | | |

<*> Гаризачылар – физик зат булган очракларда

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге